ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Балык бистэсе | Рыбно- Слободский
муниципаль районы | муниципальный район
Корноухово авыл жирлегенен | ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ | Корноуховского сельского поселения
422644, Корноухово, | 422644, Корноухово,
Совхоз урамы, 3 | ул. Совхозная, 3

Тел.: (84361) 27205, факс: (84361) 27205, e-mail:Kuh.RS @tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** КАРАР

**2018 елның 13 июне** **Корноухово ав.** **№ 15**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге
территориясендә 2018-2019 елларга терроризмны
һәм экстремизмны профилактикалау
программасын раслау турында

«Экстремизмга каршы тору турында» 25.07.2002 елдагы 114-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы, 1 ст.1 ө. 7.1 пункты нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 14 статьясы нигезендә, террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук җирлек чикләрендә терроризм һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү максатларында, «Терроризмга каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законга, «2018-2019 елларга Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча республика максатчан программасын раслау турында" 2011 елның 21 декабрендәге 1043 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге территориясендә 2018-2019 елларга терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау буенча программаны расларга (№1 кушымта).

2. 2018-2019 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге территориясендә терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау программасын тормышка ашыру буенча төп чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегенең Корноухово авылы, Совхоз урамы, 3 йорт ; Чирмешан авылы, Советлар урам, 21 йорт; Зюзино авылы, Үзэк урам, 6 йорт; Наумово авылы, Наумово урамы, 3 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Татарстан Республикасы

Балык Бистәсе муниципаль районы

Корноухово авыл җирлеге Башлыгы Колчанов В.В